ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
II СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
II ЧАКЫРЫЛЫШ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июль, 2015 ел № 41/9

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә теркәү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү турында

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ санлы Федераль законның 27 маддәсе 4 өлеше, 2012 елның 2 октябрендәге «Сәяси партияләр турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 157-ФЗ санлы Федераль Законның 4 маддәсе 8 өлеше, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссисенең 2012 елның 5 декабрендәге «Участок сайлау комиссияләре составларының резервы формалашу һәм участок сайлау комиссияләре составларының резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибе турында» 152/1137-6 санлы карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары территориаль сайлау комиссияләренә шәһәр участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә теркәү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәрне 1-3 кушымтага нигезләнеп кертергә.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары территориаль сайлау комиссияләренә җибәрергә.

Шәһәр Хакиме
вазифаларын башкаручы Ф.И. Андреева